ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш); 2024, № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы Рәисенең ихтыярыйлык (волонтерлык) өлкәсендәге вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, аларга ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренең ихтыярыйлык (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ихтыярыйлык (волонтерлык) оешмалары белән Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 2 пунктчасында каралган эшчәнлек төрләренең үзенчәлеген һәм Федераль законның $17^3$ статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә расланган гомуми таләпләрне исәпкә ала торган хезмәттәшлек тәртипләрен раслау;

2) Федераль законның $17^2$ статьясындагы 2 пункты нигезендә расланган тәртиптә Татарстан Республикасы территориясендә ихтыярыйлык (волонтерлык) ресурс үзәге функцияләрен гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешманы билгеләү.»;

2) 4 өлешнең $2^1$ пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ
БҮЛЕК
ОБЩИЙ
ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 64-ТРЗ